| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **Татарстан Республикасы**<br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЭУЖИЯК**<br>**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА**<br>**КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07 август 2025 ел № 55

Кәүҗияк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 31.03.2025 ел, №48 карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында " 31.05.2025 № 828 карарының 2 пунктындагы м пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кәүҗияк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 31.03.2025 ел, № 48 карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

17 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Россия Федерациясе субъектының оешмалар табышына салым һәм Оешмалар мөлкәтенә салым буенча ташламаларга бәйле стимуллаштыручы салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү максатларында әлеге карарның 16 һәм 18 пунктлары нигезендә әлеге салым чыгымнарының җыелма бюджет эффектын (үз-үзен аклый алуын) бәяләүне исәпләп чыгару тәкъдим ителә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Ф.Ә. Хөснетдинов